**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 7 декабреннән №12

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
Иске Гришкино авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы белән, Менделеевск муниципаль районы «Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Менделеевск муниципаль районының 2020 елның 8 апрелендәге 131 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Иске Гришкино авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1. Нигезләмәнең 11 статьясындагы 5 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорда муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый»

1.2. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 3 пунктының 4 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru "Иске Гришкино авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Иске Гришкино авыл җирлеге
Советы Рәисе В.В. Мамакова